Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Кызыл Мишә “Акчәчәк” балалар бакчасы
мәктәпкәчә белем муниципаль учреждениесе

# 2025-2026 нчы уку елына тематик план

РАСЛЫЙМ
Бакча мөдире: Гаттарова С.З.
Боерык№67 28.08.2025

Педагогик киңәшмәдә кабул ителде
Беркетмә№1 29.08.2025

# САБА РАЙОНЫ Кызыл Мишә“Акчәчәк”БАЛАЛАР БАКЧАСЫНЫҢ 2025-2026 УКУ ЕЛЫНА ТЕМАТИК ПЛАНЫ

| № | Тема | Вакыты | Истәлекле дата | Максат | Йомгаклау |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | **Белем көне! Исәнме балалар бакчасы!** | 01-06 сентябрь | 1 сентябрь-белем көне | Балалар бакчасына карата ярату хисләре тәрбияләү; тәрбияче хезмәте турында күзаллауны киңәйтү, тәрбияче хезмәтенә ихтирам хисләре тәрбияләү.Балаларда белем алуга омтылыш уяту.Балаланың мәктәп турында күзаллаулавын киңәйтү, юлйөрү кагыйдәләрен искә тошерү. | “Минем дустым” –рәсем бәйгесе. |
| 2. | **Минем республикам, Туган Татарстаным.** | 08– 13 сентябрь | 15 сентябрь-яфраклар көне | Күп милләтле Ватаныбыз турында белемнәрне киңәйтү һәм тирәнәйтү. Балаларны татар мәдәнияте белән таныштыру: гореф-гадәтләр, гореф-гадәтләр, көнкүреш, милли костюмнар. Татарстан Республикасы символикасын карарга: герб, флаг. Татар халкына, аның мәдәниятенә карата хөрмәт тәрбияләү һәм кызыксыну уяту. | Татарстан республикасы турында альбомнар карау. |
| 3. | **Сабам минем – туган ягым.** | 15– 20 сентябрь | 18 сентябрь-электрон китаплар көне | Туган як табигатенә, чишмәләргә, су буйларына карата сакчыл караш тәрбияләү.Саба районы турында белемнәрен тирәнәйтү. Сабаның символикасы һәм аның мәгънәсе белән таныштыру. Халкыбызга карата ихтирам, горурлык хисләре тәрбияләү, милли тәрбия бирү, туган якка карата ярату хисләре тәрбияләү. | Саба районы турында альбомнар карау. |
| 4. | **Исәнме Алтын көз!** | 22-27 сентябрь | 27сентябрь-Бакча хезмәткәрләре көне | Балаларда көзге табигатьнең матурлыгына соклана белү, күзәтүчәнлек һәм кызыксынучанлык сыйфаты тәрбияләү. Көзге табигатьнең матурлыгына соклана белү сыйфатларын тәрбияләү.Балаларның иҗади күзаллауларын, бәйләнешле фикерләү сәләтен үстерү. Көз турында белемнәрен тирәнәйтү. | “Исәнме, Алтын көз!”-экскурсия. |
| 5. | **Яшелчәләр,җиләк-җимешләр, гөмбәләр.** | 29 ноябрь – 04 октябрь | 1 октябрь-Өлкәннәр көне<br>5 октябрь-Укытучылар көне | Яшелчәләр, җиләк-җимешләр, гөмбәләр турындагы белемнәрен системалаштыру, алган белемнәрен уен барышында киңрәк һәм иҗади якын килеп файдалану күнекмәләрен камилләштерү. | “Уныш бабайда кунакта”- бәйрәм чарасы |
| 6. | **Кул белән ясалган дөнья. Предметлар һәм материаллар.** | 06-11 октябрь | 11 октябрь-Бөтендөнья кызлар көне | Балаларга кул белән ясалган, кул белән ясалмаган әйберләр турында мәгълүмәт бирү. Кеше ихтыяҗлары турында белемнәрен киңәйтү. | “Табышмак әйтәм, җавап тап” |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 7. | **Икмәк –безнең байлыгыбыз.** | 13- 18 октябрь | 16 октябрь- Әтиләр көне | Балаларның өстәлдә икмәк барлыкка килүе турында күзаллауларын киңәйтү. Икмәк ясауда катнашы булган кешеләрнең һөнәрләре турында сөйләү. Икмәккә, аны барлыкка китерүче кешеләрнең хезмәтенә сакчыл караш тәрбияләү. Икмәктән пешерелгән ризыклар үсеп килүче организм өчен файдалылыгы турында күзаллау бирү. | Камырдан төрле пешкән ризык рәсемнәре карау. |
| 8. | **Йорт хайваннары һәм кошлары.** | 20-25 октябрь | 23 октябрь- Бөтендөнья ак барс көне | Балаларда йорт хайваннарына, кошларга карата кызыксыну һәм сакчыл караш тәрбияләү. Хайваннарның, кошларның кышка ничек җайлашуы турындагы белемнәрне арттыру. | “Минем яраткан хайваным” рәсем бәйгесе. |
| 9. | **Кыргый хайваннар. Табигатьтә үзара бәйләнешләр. Азык чылбыры.** | 27 октябрь 01 ноябрь | 28 октябрь- Бөтендөнья анимация көне | Балаларда кыргый хайваннарга, кошларга карата кызыксыну һәм сакчыл караш тәрбияләү. Тышкы билгеләренә (зурлыгы, үз-үзләрен тотышларына, тавышларына) карап, кыргый һәм йорт хайваннарын аерып күрсәтә белү күнекмәләрен үстерү. | “Минем яраткан җәнлегем яки кошым"-рәсем бәйгесе . |
| 10. | **Без Рәсәй илендә яшибез. Бердәмлек көне.** | 03-08 ноябрь | 4 ноябрь- Бердәмлек көне. | Балаларның Рәсәй турында белемнәрен туган ил буларак ныгыту, шәһәрләр, символлар, традицияләр белән танышу. Россия Федерациясе (Россия) зур күп милләтле ил дигән күзаллаулар формалаштыру. Төрле милләт кешеләренә һәм аларның гореф-гадәтләренә хөрмәт тәрбияләү. Мәскәүнең истәлекле урыннары, архитектура һәм борынгылык һәйкәлләре белән таныштыру; Мәскәүнең төп мәйданы ни өчен кызыл дип аталуын аңлату; ныгыту, шәһәрләр, символлар, традицияләрбелән танышу, балаларга «патриотизм» сүзенең мәгънәсен аңлату. | “Илебез буенча сәяхәт” презентация карау; Дымка, хохлома, жёстов, городец бизәкләреннән күргәзмә. |
| 11. | **Җансыз табигать. Һаваның әһәмияте.** | 10- 15 ноябрь | 18 ноябрь Кыш бабайның туган көне | Балаларнын тирә - юнь, үсемлекләр, һава тере булмаган табигать турында белемнәрен киңәйтү. Табигать матур булганда гына: челтерәп чишмәләр акканда кошлар сайраганда, һава саф булганда, үләннәр яшел булганда гына безнең күңелләребез күтәренке була. Иҗади уйлау сәләтен үстерү, татар халкының мәдәниятенә мәхәббәт тәрбияләү. | “Иң матуры минем рәсем”- рәсем бәйгесе |
| 12. | **Әниләр көне!** | 17-22 ноябрь | 20 ноябрь- Бөтендөнья балалар көне | Балаларны әниләр көне иң олы бәйрәм турындагы белемнәрен тулыландыру.Әбиләргә, әниләргә карата ихтирамлы мөнәсәбәт тәрбияләү. | "Әнием бердәнберем”- күңел ачу кичәсе. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 13. | **Күчмә, кышлаучы кошлар тормышы.** | 24-29 ноябрь | 30 ноябрь Россия Федерациясенең гербы көне | Балаларда күчмә, кышлаучы кошларга карата кызыксыну һәм сакчыл караш тәрбияләү. Кучмә кошларның тормышы, кышлаучы кошларның кышка ничек җайлашуы турындагы белемнәрне арттыру; кышкы салкын көннәрнең кошлар, хайваннар, кешеләр өчен иң авыр вакыт булуын ачыклау. | Табышмаклар кичәсе. |
| 14. | **Ак ефәктән кыш килде.** | 01-06 декабрь | 3 декабрь-инвалидлар көне | Кыш, кар үзенчәлекләре турында балаларның белемнәрен тирәнәйтү; табигатьтә ел фасыллары буенча барган үзгәрешләр турындагы белемнәрне табигатькә хас билгеләр турындагы ныгыту; балаларны әдәби әсәр аша кышның тасвирланышы белән таныштыру. | “Ак мамыктай ап-ак кышны сагынып көттек без”-рәсем бәйгесе |
| 15. | **Сәнгать атналыгы. Балалар өчен язучылар, шагыйрьләр һәм рәссамнар иҗаты.** | 08-13 декабрь | 9 декабрь батырлар көне. 12 декабрь Россия Федерациясенең конституция көне | Балаларда милли мәдәният турында бербөтен күзаллау булдыру – туган телеңне белү һәм шул телдә аралашу; халык авыз иҗатын өйрәнү; туган як табигатен, милли халык уеннарын белү.Балаларда татар милли мәдәниятенә карата хөрмәт уятуБалалар өчен язучылар, шагыйрьләр һәм рәссамнар иҗаты белән танышу. | “Минем яраткан әкият героем”-рәсем бәйгесе. |
| 16. | **Җансыз табигать. Файдалыказылмалар.** | 15– 20 декабрь | | Балаларда файдалы казылмаларга кызыксыну уяту;табигый-фәнни һәм экологик белемнәрне киңәйтү, эзлеклелекне тәэмин итү; .балаларда кәеф күтәренкелеге булдыру, балаларда шәфкатьлелек,мәрхәмәтлелек, ярдәмчеллек кебек күркәм сыйфатлар тәрбияләү. | Әңгәмә: “Нинди файдалы казылмалар беләбез?” |
| 17. | **Хуш киләсең, яңа ел!** | 22-31 декабрь | 28 декабрь-Бөтендөнья кино көне. 31декабрь Яңа ел | Яңа ел бәйрәме, аңа бездә һәм башка илләрдә ничек әзерләнүләре, нинди әкият геройлары килүе, Кыш бабай, Кар кызы һәм башка илләрдә Яңа елны каршылау гореф-гадәтләре турында күзаллауларны киңәйтү.Балаларда бәйрәмнәргә карата уңай мөнәсәбәт, үз фикереңне бер юнәлештә туплый һәм аны башкаларга җиткерә белү сыйфаты тәрбияләү. Балаларда күтәренке кәеф, шатлык хисләре булдыру; күңел ачуларда катнашасы килү теләге уяту. | Хуш киләсең, яңа ел!-бәйрәм кичәсе. |
| 18. | **Кул белән ясалган дөнья.Ресурсларны икенче кабат куллану.** | 05– 10 Гыйнвар | 11 январь-Бөтендөнья “Кар бабай” көне | Балаларга кул белән ясалган әйберләр турында мәгълүмәт бирү. Кеше ихтияҗлары турында белемнәрен киңәйтү. Көнкүреш калдыклары турында белемнәрен арттыру. | Экологик уен. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 19. | **Минем өем. Минем гаиләм.** | 12– 17 гыйнвар | 14 декабрь- Искечә Яңа ел | Балаларда гаилә әгъзаларына карата ихтирамлы мөнәсәбәт, ярдәмләшү һәм дуслык тәрбияләү.Балаларның һөнәрләр турындагы белемнәрен баету, тирәнәйтү, мөстәкыйль һәм гомумиләштереп фикерләү сәләтен үстерү, төрле һөнәр ияләренә карата кызыксынучанлыкларын үстерү. | Һөнәрләр илендә" Уенинсценировка. |
| 20. | **Халык мәдәнияте һәм традицияләре атналыгы. Халык бәйрәмнәре.** | 19- 24 гыйнвар | 21 гыйнвар – Бөтендонья кочаклашу көне | Балаларда туган телебезгә, туган илебезгә, халкыбызның рухи хәзинәләренә мәхәббәт тәрбиләү.Балаларны татар халкының рухи мирасы, күңел җәүһәрләре белән таныштыру. Халкыбызның милли киемнәренә һәм бизәнү әйберләренә кызыксыну тәрбияләү. | Күмәк уеннар уйнау. Татар халык уеннары. |
| 21. | **Мин дөнья кешесе!** | 26 гыйнвар- 31 гыйнвар | 27 январь- Ленинградны фашистлардан азат итү көне | Балаларда әхлакый сыйфатлар, әти-әнигә хөрмәт тәрбияләү;балаларның гаиләдәге хокуклары турындагы белемнәрен ныгыту, аларның ялга, уенга хокуклы булуларын аңлату; балаларга дус булырга кирәклеген төшендерү, аларда дуслык, әхлаклылык хисләре тәрбияләү; кеше бер-берсе белән, нинди милләттән булуына карамастан, туганнарча аралашып яшәүгә хокуклы булу төшенчәсен бирү. | "Минем яратуга һәм кайгыртуга хокукым бар" темасына рәсем күргәзмәсе. |
| 22. | **Юл йөрү кагыйдәләре. Заманча транспортлар.** | 02-07 февраль | 8 февраль- Россиянең фән көне | Балаларда транспорт йөртүче һөнәр ияләренә карата ихтирам һәм урамда, җәмәгать транспортында үз-үзеңне тоту күнекмәләре тәрбияләү.Коры җир, су һәм һава транспорты чараларын аера белергә, аларны чагыштырырга, төркемнәргә аерырга өйрәтүне дәвам итү, һәр төр транспорт турындагы күзаллауларын киңәйтү. Балаларның юл йөрү кагыйдәләре турында белемнәрен камилләштерү. | Рәсем бәйгесе. |
| 23. | **Туган тел атналыгы. М. Җәлил – халык улы.** | 09– 14 февраль | 15 февраль – М.Җәлил туган көне | Балаларда туган телебезгә, туган илебезгә, халкыбызның рухи хәзинәләренә мәхәббәт тәрбиләү.Балаларны татар халкының рухи мирасы, күңел җәүһәрләре белән таныштыру.Халкыбызның милли киемнәренә һәм бизәнү әйберләренә кызыксыну тәрбияләү.Балаларда патриотик хисләр тәрбияләү.Балаларны Муса Җәлил тормыш юлы һәм иҗаты белəнтаныштыруны дәвам итү, әдәби әсәрләрен тыңлау һәм сөйләү теләге уяту. | Шагыйрьнең бер шигыренә рәсем ясау. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 24. | **Әдәпле сүзләр һәм яхшы гадәтләр дөньясында.** | 16 -21 февраль | 21 февраль-Бөтендөнья телләр көне.<br>23 февраль-Ватанны саклаучылар көне | Балаларда кунакчыллык, кунакларга карата хөрмәт сыйфатлары тәрбияләү. алаларда савыт-сабага карата сакчыл караш тәрбияләү. Балаларда киемнәргә карата зәвык, сакчыл караш тәрбияләү.Балаларның күзәтүчәнлекләрен, логик фикерләү сәләтен, диалогик һәм монологик сөйләмен үстерү. | “Әтием солдат булган” балалар кичәсе. |
| 25. | **Батырлыкта-матурлык.** | 23 февраль 28 февраль | 23февраль-Ватанны саклаучылар көне | Балаларда кыю, батыр солдат булу теләге уяту, әтиләре, абыйлары белән горурлану хисе тәрбияләү. Ватанны саклаучылар турындаы күзаллауларын киңәйтү,бәйләнешле сөйләм үстерү. Җирне, күкне, диңгезне саклаучылар турында белем бирү, аларның мөһимлеген аңлату. | “Иң күп тәмле сүз” викторина үткәрү. |
| 26. | **Халык-ара хатын кызлар бәйрәме!** | 02– 07 март | 8 март-Бөтендөнья хатын- кызлар көне | Балаларны язгы табигать белән таныштыру.Язгы табигатьтәге үзгәрешләрне күрә белергә һәм яз килүгә сөенү хисләре тәрбияләү.Балаларда яз турында белемнәрен мөстәкыйль эшчәнлектә иҗади куллана белү күнекмәләрен үстерү.Балаларда әниләргә карата ихтирам, хөрмәт хисләре тәрбияләү. | “Иң кадерлем - әнием!” -бәйрәм иртәсе. |
| 27. | **“Яз килә, яз килә, елмаеп кояш көлә!” Яз көне кошлар, җәнлекләр тормышы.** | 09– 14 март | 12 март-Интернетның туган көне | Балаларны язгы табигать белән таныштыру.Язгы табигатьтәге үзгәрешләрне күрә белергә һәм яз килүгә сөенү хисләре тәрбияләү.Балаларда яз турында белемнәрен мөстәкыйль эшчәнлектә иҗади куллана белү күнекмәләрен үстерү. | “Табышмак әйтәм, җавап тап” |
| 28. | **Җансыз табигать.Су яшәү чыганагы.** | 16- 21 март | 18 март-Крымның Россияга кушылган көне | Яшәү чыганагы булган суга сак караш һәм мәхәббәт тәрбияләү.Балаларны суның үзлекләре, табигатьтә һәм кеше тормышында аның ролен аңлату. | Су белән төрле экспериментлар үткәрү. |
| 29. | **Бөтендөнья театр көне. Балаларның китап атналыгы.** | 23-28 март | 27 март-Бөтендөнья театр көне | Балаларны Бөтендөнья театр көне белән таныштыру.Китап, аның кайдан килүе, китапханәче хезмәте турында балаларның белемнәрен киңәйтү; китапханә белән турыдан-туры таныштыру аша балаларда күзәтүчәнлек, игътибарлылык, эзлекле фикерләү сәләтен үстерү; китапханәче һөнәренең мөһимлеген аңлату.Китап карау, укуга, белемгә омтылыш тәрбияләү;китапларга карата сак караш, хөрмәт тәрбияләү. | Китапханәгә экскурсия. |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 30. | **Мин үземне беләм. Минем сәламәтлек!** | 30 март 04 апрель | 1 апрель- көлке көне | Балаларда үз сәламәтлекләренә карата игътибарлылык, сак караш тәрбияләү.Балаларның үз фикерләрен дөрес итеп җиткерә белү күнекмәләрен үстерү, сәламәт яшәү рәвешенә омтылыш булдыру.Балаларга сәламәтлекне саклауда табигатьнең әһәмиятен аңлату, чыныгу чаралары белән таныштыру. | “Спортландия” - хәрәкәтле ял кичәсе. |
| 31. | **Техник прогресс. Галәм киңлекләре.** | 06-11 апрель | 12 апрель- космонавтика көне | Балаларга галәм туында һәм кояш системасы турында белем бирү.Космонавтика көне турында белемнәрен формалаштыру.Балаларның кызыксынучанлыгын, алган белемнәрен мөстәкыйль куллана белү сәләтен үстерү. | Космоска юл-рәсем, аппликация конкурсы. |
| 32. | **Куркынычсызлык. Уттан саклан.** | 13-18 апрель | 18 апрель- һәйкәлләр көне | Балаларны янгын килеп чыгу сәбәпләре белән таныштыру. Балаларда игътибарлылык, күзәтүчәнлек тәрбияләү. Балаларныкуркынычсызлык кагыйдәләре белән таныштыруны дәвам итү. | Тренировка үткәрү-янгын очрагында эвакуация планы буенча чыгу |
| 33. | **Г.Тукай безнең күңелләрдә** | 20-25 апрель | 22 апрель- Бөтендөнья җир көне.<br>26 апрель Г.Тукай туган көн. | Балаларны Габдулла Тукайның тормыш юлы һәм иҗаты белән таныштыруны дәвам итү, әдәби әсәрләрен тыңлау һәм сөйләү теләге уяту.Таныш әдәби сюжетлар буенча Г.Тукай иҗаты буенча алган белемнәрен камилләштерү.Иҗатка кызыксынучанлыкларын үстерү. | “Кәҗә белән Сарык сәфәре “- бәйрәм иртәсе. |
| 34. | **Җир шары – безнең уртак йортыбыз. Төньяк һәм көньяк илләре һәм анда яшәүче хайваннар.** | 27 апрель 02 май | 1 май- Яз һәм хезмәт бәйрәме | Балаларны төньяк һәм көньяк илләре белән таныштыру.Балаларны төньяк һәм көньяк илләре һәм анда яшәүче халыклар, хайваннар, үсемлекләре белән таныштыру. | “Төньяк һәм көньяк илләре һәм анда яшәүче хайваннар”- рәсем бәйгесе |
| 35. | **Җиңү алып килгән яз** | 04-09 май | 9 май- Җиңү бәйрәме | Балаларда патриотик хисләр, туган якка, туган телгә, Ватанга мәхәббәт тәрбияләү.Ветераннарыбызның Бөек Ватан сугышында күрсәткән батырлыклар турында белемнәрен кинәйтү. | Митингта катнашу. |
| 36. | **Тере табигать. Урман. Бөҗәкләр.** | 11-16 май | 19 май - Россия балалар иҗтимагый оешмалары көне | Чәчәкле үсемлекләрнең төрлелеге, аларның яшәү урыны белән бәйләнеше белән танышу. Балаларның чәчәк атучы үсемлекләр һәм аларның төрлелеге турындагы күзаллауларын киңәйтү һәм төгәлләү. Төшенчәләрне ныгыту: бүлмә, бакча, болын, дару үсемлекләре. Үсемлекләргә сакчыл караш формалаштыру, аларны карау теләген үстерү. Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгына мәхәббәт тәрбияләү. | “Урман аланына сәяхәт”-рәсем бәйгесе |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| 37. | **Бүлмә һәм бакча гөлләре.** | 18-23 май | 24 май Славян язуы һәм мәдәнияте көне | Чәчәкле үсемлекләрнең төрлелеге, аларның яшәү урыны белән бәйләнеше белән танышу. Балаларның чәчәк атучы үсемлекләр һәм аларның төрлелеге турындагы күзаллауларын киңәйтү һәм төгәлләү. Төшенчәләрне ныгыту: бүлмә, бакча, болын, дару үсемлекләре. Үсемлекләргә сакчыл караш формалаштыру, аларны карау теләген үстерү. Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгына мәхәббәт тәрбияләү. | “Чәчәкләр иленә сәяхәт” (Бакчаның яз чәчәкләре белән тәрәз төбендәге гөлләр танышу) |
| 38. | **Тиздән җәй!** | 25-30 май | 31 май- Бөтендөнья мәдәният көне | Балаларны ел фасылы буларак – җәй, табигатьтәге үзгәрешләр, милли гореф-гадәтләр белән таныштыруны дәвам итү. Балалар бакчасында өйрәнгән белемнәрне гомумиләштерү.Әйләнә-тирә дөньяның матурлыгына мәхәббәт тәрбияләү. | “Сабантуй” бәйрәмен үткәрү. |